**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2017 Балык Бистәсе штп. № 245пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 31 декабрендә “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2014 – 2019 елларга муниципаль хезмәтне үстерү Программасын раслау турында”гы 263пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2014 – 2019 елларга муниципаль хезмәтне үстерү Программасына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы Федераль законга, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге “”2014 – 2019 елларга Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү” дәүләт программасын раслау турында” 910 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге “”2014 – 2019 елларга Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү” дәүләт программасын раслау турында” 910 номерлы карары белән расланган “”2014 – 2019 елларга Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү” дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 6 октябрендәге 763 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма

комитетының 2013 елның 31 декабрендә “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2014 – 2019 елларга муниципаль хезмәтне үстерү Программасын раслау турында”гы 263пи номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 мартындагы 48пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында 2014 – 2019 елларга муниципаль хезмәтне үстерү Программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның паспортында:

“Программаның бурычлары” юлының 3 пунктын “муниципаль хезмәткәрләрнең” сүзләреннән соң “,җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны алмаштыручы хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

“Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре” юлының 7 пунктын “муниципаль хезмәткәрләрнең” сүзләреннән соң “,җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны алмаштыручы хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

Программаның II бүлегенең алтынчы абзацын “муниципаль хезмәткәрләрнең” сүзләреннән соң “,җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны алмаштыручы хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

1 номерлы кушымтада:

“Бурыч: “Муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә итү компетентлыгын үстерү” юлын “муниципаль хезмәткәрләрнең” сүзләреннән соң “,җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны алмаштыручы хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

2 номерлы кушымтада:

“Бурыч: “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең, шулай ук күрсәтелгән җирле үзидарә органнарының кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә итү компетентлыгын үстерү” (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) юлын “( алга таба – муниципаль хезмәткәрләр)”сүзләреннән соң “,җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны алмаштыручы хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

“Муниципаль хезмәткәрләрнең ( муниципаль вазыйфаларны алмаштыручы затларның) квалификациясен күтәрү, һөнәрләрен яңадан хәзерләүне оештыру” 1 пунктының 2 графасын “җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны алмаштыручы

хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең" сүзләре белән тулыландырырга;

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына локаль хокукый актларны әлеге карарның 1 пункты белән кертелүче үзгәрешләргә туры китерү максатларында эшләп бетерергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Х. Хабибуллин